**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
«Войкино авыл җирлеге» Войкино авыл торак пунктында гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында

**2023 елның 10 октябреннән** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 10 октябрендә узган гражданнар җыенының нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде, түбәндәге сорау буенча «Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Войкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Войкино торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 600 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан,көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

-торак пункт юлларын төзекләндерү;

-торак пункт юлларын кышкы һәм җәйге чорда тоту;

-һәйкәлнең тирә-ягындагы территорияне карап тоту;

- урамнарны яктыртуны карап тоту;

-чишмәне төзекләндерү;

- су белән тәэмин итү челтәрләрен карап тоту».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукы булган 136 кеше кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 117 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

«ЯКЛЫЙМ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 117 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Алексеевск муниципаль районы Войкино авыл җирлегендәге Войкино авыл торак пунктында гражданнар җыены булып узды дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2.Сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга: «Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Войкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Войкино торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә

укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

-торак пункт юлларын төзекләндерү;

-торак пункт юлларын кышкы һәм җәйге чорда тоту;

-һәйкәлнең тирә-ягындагы территорияне карап тоту;

- урамнарны яктыртуны карап тоту;

-чишмәне төзекләндерү;

- су белән тәэмин итү челтәрләрен карап тоту».

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Войкино авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Войкино авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы
Войкино авыл җирлеге башлыгы

Н.П. Шабутдинова
(имза) (имзаның расшифровкасы)